ГЛАВА КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Постановление

**“ 27 ” октябрь 2020 г.** — **№ 2**

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенең Көмеш-Күл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көмеш-Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Көмеш-Күл авылы , Үзәк урамы , 103 нче йорт адресы буенча урнашкан Көмеш-Күл авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 19 ноябрендә сәгать 18.00 Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенең Көмеш-Күл авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенең Көмеш-Күл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

**- ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл торак пунктында, Көмеш- Күл авыл җирлегендә яңа урам яктырткычлары сатып алу, ремонтлау һәм урнаштыру.**

**- Көмеш-Күл торак пунктында зират коймасын урнаштыру.**
**-ТР Мамадыш муниципаль районы Көмешкүл авыл җирлегенең Көмеш-Күл торак пунктында Үзәк урамын вакташ җәеп ремонтлау**
**Көмеш-Күл торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.**

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге башкарма комитетына Көмеш-Күл авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы: И.Н.Салахутдинов